# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлеге составына керүче Югары Налим торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**17.11.2022** **№ 2**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2022 елның 17 нче ноябрендә булып узган гражданнар җыены нәтиҗәләре нигезендә сорау буенча бе ркетмә төзелде: "Сез 2023 елда Югары Налим авыл җирлегенең Югары Налим торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндез белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга сез ризамы:

- Сабантуй үткәрү урынын төзекләндерүгә;
- зират эчендәге карт агачларны кисүгә;
- Елга аръягы, Тукай урамнарында чокырларны ремонтлауга;
- Яшьләр урам юлына дренаж өчен торба салуга.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 231 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 143 кеше кертелгән.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен 143 җыенда катнашучы тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен 0 җыенда катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Югары Налим авыл җирлегенең Югары Налим торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре-дөрес.

2. «Сез 2023 елда Югары Налим авыл җирлегенең Югары Налим торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым акчаларын кертүгә, көндез белем алучы студентлардан, I төркем инвалидлардан, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан кала, һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге түбәндәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотуга сез ризамы:

- Сабантуй үткәрү урынын төзекләндерүгә;

- зират эчендәге карт агачларны кисүгә;

- Елга аръягы, Тукай урамнарында чокырларны ремонтлауга;

- Яшьләр урам юлына дренаж өчен торба салуга”. – соравы буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Карарны кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге мәгълүмат стендларында, Зәй муниципаль районы рәсми сайтының «Авыл җирлекләре» бүлегендә, «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Югары Налим авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Налим авыл җирлеге башлыгы Л.И. Сибгатуллин